ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.03.2021 г. Заинск № 190

**"Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында" 2019 елның 17 декабрендәге 644 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында"**

Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү, мәктәпкәчә белем бирүдә бюджет мәгариф хезмәтләренең сыйфатын арттыру максатларында, «Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 02 июлендәге 546 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 17 декабрендәге 644 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләү тәртибе» 1 нче кушымтасына, 2.6 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Халыкның җәмәгать туклануын оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләрне раслау турында» СанПиН 2.3/2.4.3590-20 санитар-эпидемиологик кагыйдәләрне һәм нормаларны раслау турында» 2020 елның 27 октябрендәге 32 номерлы Россия Федерациясенең баш дәүләт санитария табибы карары нигезендә кабул ителгән тәрбияләнүчеләрне тукландыру нормасы».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Л.Р. Печина
3-27-42